ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№1 08 ноябрь 2024 ел

«Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Мокшино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2024 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы, Яңа Мокшино авылы, Ленин урамы, 20 йорт адресы буенча урнашкан яңа Мокшино күпфункцияле үзәге бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Мокшино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасында укучы, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгәннәрне) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (автоматика, электрүткәргечләр, тоташтырулар һәм башка товарлар сатып алу, су җыю манарасы территориясен койма белән әйләндереп алу).

РИЗА КАРШЫ

3. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең күпләп җыела торган урыннарына, стендларга һәм такталарга белдерүләр элү юлы белән халыкка җиткерергә, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы Н.В.Айдова